**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.09.2014 № 491

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 10 октябрендә теркәлде, № 2447

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә
эшеннән җибәрелеп, башка эшкә урнашмаган
хатын-кызларга айлык компенсация түләүләре
билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында”
06.06.2012 ел, №395 Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы боерыгына
үзгәрешләр кертү хакында

Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, башка эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 06.06.2012 ел, №395 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”;

Боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга

айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) (кушымта итеп бирелә) расларга.”;

2. Боерык белән расланган Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламент атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты”;

1 бүлектә:

1.1 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.1. Бу Административ регламент (алга таба – Регламент) оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.”;

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәте алучы яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә вәкаләт бирелгән зат.”;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә тормышка ашырыла:

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, №210-ФЗ Федераль закон (алга таба – №210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, №63-ФЗ Федераль закон (алга таба – №63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, №15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Гражданнарның аерым категорияләренә компенсация түләүләре күләме турында” 30 май, 1994 ел, №1110 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – №1110 РФ Президенты Указы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1994, №6, 589 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Гражданнарның аерым категорияләренә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм түләү тәртибен раслау турында” 3 ноябрь,1994 ел, №1206 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган

Гражданнарның аерым категорияләренә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм түләү тәртибе (алга таба – Тәртип) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1994, №29, 3035 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эштән җибәрелеп, 3 яшькә кадәрге балалары булган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык компенсация түләүләрен финанслау турында” 4 август, 2006 ел” №472 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, №33, 3633 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында” 05.12.2005 ел, №563 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №563 ТР МК карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 2005 ел, №47-48, 0985 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007 ел, №388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №388 ТР МК карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007 ел, №33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, №880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010 ел, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып).”;

түбәндәге эчтәлектәге 1.5 пунктны өстәргә:

“1.5. Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны аңлата (№210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты). Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы бу Регламентка № 1 кушымтада китерелә.”;

2 бүлектә:

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.5 пунктның 1-5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мөрәҗәгать итүче компенсация алу өчен тапшыра:

1. Гариза (бу Регламентка №1 кушымта).

2. Бала карау буенча ял бирү турында боерык күчермәсе.

3. Хезмәт кенәгәсе күчермәсе.

4. Нотариуста расланган яки Россия федерациясе Гражданлык кодексының 185.1 статьясында һәм Россия Федерациясе Гражданлык-процессуаль кодексының 53 статьясында күрсәтелгән оешмалар һәм учреждениеләр раслаган ышанычнамә (ышанычлы зат мөрәҗәгать иткәндә).";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Балаларны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлардан торган документлар (ЗАГС органнарында).

2. Эшсезлек буенча пособие алмау турында мәгълүматлардан торган документлар (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарында).

Мөрәҗәгать итүче әлеге документларны турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә алырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтеп үтелгән документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тора алмый".

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.8 пунктының 1 пунктчасына ", яки аның ышанычлы заты тарафыннан" дигән сүзләр өстәргә;

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.9 пунктының 6 пунктчасына түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6.Гариза һәм документлар электрон рәвештә җибәрелгән очракта, №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 таләпләре нигезендә имзаланмаганда, документларның төп нөсхәләрен һәм закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен тапшырмау";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1. документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

2. дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3. дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан регламентны бозу очраклары (нигезле шикаятьләр) булу-булмау ( мондый очракларның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гомуми санына карата нисбәте).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора:

1. территориаль социаль яклау органының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы;

2.белгечләрнең кирәкле санда булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен кирәкле бүлмәләрнең тиешле санда булуы;

3.Министрлыкның мәгълүмати стендларында, "Интернет" челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

4. электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге.”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.16 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Документлар (документлар күчермәләре) электрон документлар рәвешендә җибәрелеп, №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 таләпләре нигезендә имзаланмаган очракта, компенсация билгеләү мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлек) бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән кәгазьдәге документларның төп нөсхәләрен яки закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен күрсәткәч хәл ителә.”;

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.16 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны кертеп, МФЦ аша хәл ителми.”;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1. Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар булдырып җибәрү;

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләрнең эзлеклелегенең блок–схемасы №4 кушымтада китерелгән.”;

3.2 пункт атамасына “, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан” дигән сүзләр өстәргә;

3.2 пунктта икенче абзацка “дәүләт хезмәте күрсәтә” дигән сүзләрдән соң “һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан” дигән сүзләр өстәргә;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар булдырып җибәрү.

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мәгълүматларны тапшыру турында электрон рәвештә запрослар булдырып җибәрә:

ЗАГС органнарына 2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларны дәүләт теркәвенә алу турында (2015 елның 1 гыйнварыннан сорала);

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүматлар тапшыру турында запрос.

3.4.2.Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә мәгълүматлар ала:

ЗАГС органнарыннан 2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләреннән эшсезлек буенча пособие алмау турында.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүматлар алу.”;

3.5 пунктта дүртенче абзацка “электрон рәвештә” дигән сүзләрдән соң “, №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 таләпләре нигезендә имзаланмаган,” дигән сүзләр өстәргә;

3.7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү МФЦ аша хәл ителми.”;

4 бүлектә 4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.4. Гражданнар, аларны берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге нигезендә хәл ителә.”;

5 бүлектә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе”;

5.3. пунктның икенче абзацында “почта аша,” дигән сүзләрдән соң “МФЦ аша” дигән сүзләр өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге 5.9. пунктны өстәргә:

“5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.”;

Регламентка № 1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №1 кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

________________________________

(муниципаль район (шәһәр округы)
Идарәсенә (бүлек)

**ГАРИЗА № _____**

“____” ________________ 20 __ ел

Мин, ____________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме – тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яшим: ______________________________________

( индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы)

______________________________________________________________________

| Шәхесне раслаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

1. Миңа_________________________________________________________

( алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга бирелә торган айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләүне сорыйм.

Балалар:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туганлык дәрәҗәсе | Туу турында таныклыгы, кем тарафыннан һәм кайда бирелүе | Яшәү урыны буенча теркәлү адресы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Түбәндәге документларны тапшырам:

| № | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:

счет № __________________ бүлек ______________ Банк _____________

Почта бүлеге ________________________________

Тапшырылган документларның чынлыгын һәм бәян ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.

"Персональ мәгълүматлар турында" 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон нигезендә, персональ мәгълүматларны мәгълүмат алмашу системасында җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган рәвештә, саклауга һәм өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм ________

_________________________________________________________________ ,

(дәүләт хезмәте алучының, шулай ук, гариза дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә торган зат тарафыннан тапшырылса, мөрәҗәгать итүченең ФИО күрсәтелә

_________________________________________________________________ ,

бу Гаризада күрсәтелгән ________________________________________ ,

(мөрәҗәгать итүче имзасы)

Мөрәҗәгать итүче:

_______________________________________ _________ "___"_____20__ ел.

(Дәүләт хезмәте алучының яки билгеләнгән тәртиптә расланган ышанычнамә нигезендә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүче затның ФИО) (имза)

3. Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга риза _______________________________

(язмача, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша)

"___" _______ 20___ ел. Имза __________

Гариза һәм документлар кабул ителде ___ 20__ ел _____ ____________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

_________________________________________________________________

(ерту өчен сызык)

Расписка-белдерү кәгазе

Документлар саны ____ берәмл. ______ битләрдә

Документларны кабул итте ____________ ____________ _______ 20 ___ ел.

(имза) (тулы имза) (дата)";

Регламентка № 2 кушымтада "Регламентка" дигән сүзне "Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына" дигән сүзләргә алыштырырга;

Регламентка № 3 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты№ 3 кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

________________________________

(муниципаль район (шәһәр округы)
Идарәсенә (бүлек)

Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында

**КАРАР**

№ _________ __________ 20_____ ел

айлык акчалата компенсация ______________________________
билгеләргә (билгеләүдән баш тарту)

оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга бирелә

торган_________________________________________________________________,

(алучының ФИО)

Айлык акчалата компенсация күләме________________________________ сум.

Түләү чоры _________20___елдан __________________20___елга кадәр

Күчерү юлы белән түләү ысулы

Счет № ______________ бүлек __________________ Банк ____________

П/о __________________________________


Социаль яклау идарәсе (бүлек) начальнигы ___________ ____________________
М.У. (имза) (тулы имза)

Белгеч __________ ___________________.
(имза) (тулы имза)”;

Регламентка №4 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №4 кушымта

**Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы**




”;

“Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта
(белешмә)

**Оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшеннән җибәрелеп, эшеннән җибәрелгән вакытта өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган, эшсезлек буенча пособие алмый торган, эшкә урнашмаган хатын-кызларга айлык акчалата компенсация түләүләре билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш.,<br>К.Маркс ур., 8 й.,<br>Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423300, Азнакай,<br>Болгар ур., 9 й.<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-73-68<br>2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б.,<br>Ленин ур., 8 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав.,<br>Юбилей ур., 45 й.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б.,<br>Казаков ур., 8 й.<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав.в<br>Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Әлмәт муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8553) 32-45-50 | 423452, Әлмәт ш., 8 март ур., 21а й. Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84376) 2-11-84 2-10-81 | 422350, Апас ав., Шоссе ур., 5 й. Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84366) 3-13-53 3-13-33 | 422000, Арча ш., Банк ур., 6в й. Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84369) 2-16-60 2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав., Октябрь ур., 9 й. Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85569) 5-10-50 5-66-81 | 423930, Баулы ш., Җиңү мәйданы, 4 й. usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84368) 2-44-78 | 422250, Балтач ав., Һ.Такташ ур., 3а й. Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85594) 4-20-05 4-26-64 | 423230, Бөгелмә ш., Совет ур., 56 й. Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84374) 3-32-10 3-35-35 3-17-03 3-55-29 | 422430, Буа ш., Ленин ур., 52 й. Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84379) 2-17-57 2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур. Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84365) 2-32-43 | 422700, Биектау ст. т.юлчылар б., Профсоюз ур., 1а й. Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84375) 2-38-07 2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й. Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85557) 7-51-55 7-87-86 | 423600, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85558) 7-10-64 3-43-59 | 423520, Зәй ш., Крупская ур., 6 й. Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районында социаль яклау | (84371) 5-58-80 | 422540, Зеленодол ш., Ленин ур., 25 й. |

| | | |
|---|---|---|
| бүлеге | 5-79-90 | Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>К.Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77<br>3-14-52 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш.,<br>Х.Туфан проспекты, 23 й.<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районында социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык проспекты, 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав.,<br>Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55<br>2-39-88 | 423040, Нурлат ш.,<br>Мәктәп ур., 8 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык бистәсе ав.,<br>Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б.,<br>Тукай ур., 87 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-81<br>3-00-00<br>3-08-98 | 422840, Болгар ш.,<br>Хирург Шеронов ур., 13 й.<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57 | 423807, Чаллы ш.,<br>М.Җәлил проспекты, 46 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав.,<br>Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Гагарин ур., 7 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-11-50 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкий ур., 45 й.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91<br>2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б.,<br>Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан. ш. Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036 Казан ш.,<br>Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан. ш. Вахитов районы социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420043 Казан ш., Вишневский ур., 10 й.Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан. ш. Киров районы социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102 Казан ш., Г.Баруди ур., 5 й.<br>Usz. Kirov@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Казан. ш. Мәскәү районы социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095 Казан ш., Блюхер ур., 81а й Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан. ш. Яңа Савин районы социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420044 Казан ш., Ямашев пр., 37 й Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан. ш. Идел буе районы социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420059 Казан ш., Р. Зорге ур., 39 й. Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан. ш. Совет районы социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420037 Казан ш., Г.Кутуй ур., 33 й. Usz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларына функциональ аудит бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |

".

**Министр** **А.Р.Шәфигуллин**